| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МАЛОМЕМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ МӘМИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.02.2020 ел Кече Мәми ав. № 2

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл жирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә курсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-03 номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм жирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында жирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 нчы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2021 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» 2021 елның 28 гыйнварындагы 73 номерлы карары нигезендә «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл жирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымталарга туры китереп, 6424,98 сум күләмендә билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл жирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл жирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә курсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында» 2020 елның 30 гыйнварындагы 3 номерлы карарын гамәлдән чыккан дип санарга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://mmemin-kaybici.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» һәм бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Кече Мәми авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Е.Н.Алексеева

Кече Мәми  авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2021 е. «08» февралендәге
2 номерлы карарына
1 нче кушымта

**«Татарстан Республикасы Кайбыч
муниципаль районы Кече Мәми  авыл жирлеге»
муниципаль берәмлегендә җирләү буенча
хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә
курсәтелә торган хезмәтләр бәясе**

| **Хезмәтләр исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе** ***(сумнарда)*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2756,48 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка күчерү | 737,94 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2930,56 |
| **Барлыгы** | **6424,98** |

Кече Мәми авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2021 е. «08» февралендәге
2 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Кече Мәми авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе**

| **Хезмәтләр исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе *(сумнарда)*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Кәфенләү | 346,53 |
| 3. Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2409,95 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка күчерү | 737,94 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2930,56 |
| **Барлыгы** | **6424,98** |